Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVII-10**

Балык Бистәсе штп.

2022 елның 29 октябре

Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны гаммәви мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге X-6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны гаммәви мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге X-6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 16 ноябрендәге XIII-6 номерлы, 22.08.2017 елның 22 августындагы XXI-5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), 2 пунктның г пунктчасын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алар исәбеннән алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган) акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (работникның) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы
урынбасары

Ф.Г. Әхмәтҗанова